| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 14 февраль г.Казань № 84

Күчмә составның (автобусларның) финанс арендасы (лизинг) шартнамәләре буенча лизинг түләүләрен түләү чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен шәһәр эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы автотранспорт предприятиеләренә субсидия биргәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Казан шәһәре һәм Чаллы шәһәре муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Күчмә составның (автобусларның) финанс арендасы (лизинг) шартнамәләре буенча лизинг түләүләрен түләү чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен шәһәр эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы автотранспорт предприятиеләренә субсидия биргәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Казан шәһәре һәм Чаллы шәһәре муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 14 февраль, 84 нче
карары белән расланды

**Күчмә составның (автобусларның) финанс арендасы (лизинг) шартнамәләре буенча лизинг түләүләрен түләү чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен шәһәр эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы автотранспорт предприятиеләренә субсидия биргәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Казан шәһәре һәм Чаллы шәһәре муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип 2024 елда төзелгән күчмә составның (автобусларның) финанс арендасы (лизинг) шартнамәләре буенча лизинг түләүләрен түләү чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен шәһәр эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы автотранспорт предприятиеләренә субсидия биргәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Казан шәһәре һәм Чаллы шәһәре муниципаль берәмлекләре (алга таба - муниципаль берәмлекләр) бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү (алга таба шул ук эзлеклелектә – лизинг шартнамәләре, шәһәр эчендә электр транспорт белән пассажирлар йөртү һәм багаж ташу, башка бюджетара трансфертлар) механизмын, максатларын һәм шартларын билгели.

2. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык).

3. Башка бюджетара трансфертлар бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен билгеләнгән тәртиптә Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

4. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары:

пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы автотранспорт предприятиеләренә лизинг шартнамәләре буенча лизинг түләүләре түләү чыгымнары өлешен финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидияләр бирү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый акт булу;

тиешле финанс елына муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) финанслашу максаты белән башка бюджетара трансфертлар бирелә торган муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләре үтәлешенә аларны үтәү өчен кирәкле күләмдә (Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертлар күләмен кертеп) бюджет ассигнованиеләре булу;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча Министрлык һәм муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органы арасында чыгым йөкләмәләрен гамәлгә ашыру максаты белән башка

бюджетара трансфертлар бирелә торган әлеге йөкләмәләрне үтәү буенча муниципаль берәмлекнең йөкләмәләре һәм һәм килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык күздә тотыла торган башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү.

5. Башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе (алга таба – нәтиҗәлелек күрсәткече) – 2024 елда төзелгән автобуслар лизингы шартнамәләре буенча йөкләмәләрне үтәү.

6. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен муниципаль берәмлектәге вәкаләтле җирле үзидарә органы Министрлыкка түбәндәгеләрне кертә:

башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗны финанс-икътисад ягыннан нигезләү теркәлгән, ирекле формада язылган башка бюджетара трансфертлар бирү турында заявка (алга таба – заявка);

Муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органының муниципаль берәмлек бюджеты (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлеге) турындагы карарыннан муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы автотранспорт предприятиеләренә лизинг шартнамәләре буенча лизинг түләүләре өчен түләү чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булуны раслаган һәм бирергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертлар күләмен үз эченә алган өземтә;

пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы автотранспорт предприятиеләренә лизинг шартнамәләре буенча лизинг түләүләре түләү чыгымнары өлешен финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидияләр бирү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый акт күчермәсе.

7. Министрлык:

әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны алар кергән көнне терки;

заявка теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны карап тикшерә һәм башка бюджетара трансфертлар бирү турында яки башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

8. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

муниципаль берәмлек тарафыннан бу Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын үтәмәү;

әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган документлардагы мәгълүмат дөрес булмау.

9. Министрлык тарафыннан муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органына башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, әлеге карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә хәбәрнамә җибәрелә.

10. Муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органы әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә яңадан заявка бирергә хокуклы.

11. Башка бюджетара трансфертлар Министрлыкның башка бюджетара трансферт бирү турындагы карары кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә төзелгән килешү нигезендә бирелә.

12. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме;

нәтиҗәлелек күрсәткеченең зурлыгы;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе һәм сроклары;

финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында хисап, башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап бирү формасы һәм сроклары;

нәтиҗәлелек күрсәткеченең билгеләнгән зурлыгына ирешмәү нәтиҗәләре;

муниципаль берәмлектәге вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан Килешүдә каралган башка бюджетара трансфертлардан файдалану йөкләмәләре үтәлүен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

якларның килешү шартларын бозган өчен җаваплылыгы.

13. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме ($P_к$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P_к = N_к \times K_к \times 25\%,$$

монда:

$N_к$ - агымдагы елның лизинг түләүләре күләме, Казан шәһәрендә пассажирлар һәм багаж ташучы автотранспорт предприятиесе тарафыннан төзелгән лизинг килешүе нигезендә, бер автобус өчен;

$K_к$ - лизинг килешүе нигезендә Казан шәһәрендә пассажирлар һәм багаж ташучы автотранспорт предприятиесе тарафыннан лизингка алынган автобуслар саны.

Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар ($P_н$) күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P_н = N_н \times K_н \times 50\%,$$

монда:

$N_н$ - агымдагы елның лизинг түләүләре күләме, Чаллы шәһәрендә пассажирлар һәм багаж ташучы автотранспорт предприятиесе тарафыннан төзелгән лизинг килешүе нигезендә, бер автобус өчен;

$K_н$ - лизинг килешүе нигезендә Чаллы шәһәрендә пассажирлар һәм багаж ташучы автотранспорт предприятиесе тарафыннан лизингка алынган автобуслар саны.

Муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган бюджет йөкләмәләре лимитларыннан артып китә алмый.sub_102

Муниципаль берәмлекләр бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертлар бүленеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

14. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финанс органына ачылган муниципаль берәмлек бюджетының бердәм счетына күчерелә.

15. Муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органы башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына кадәр Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансферт һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап тапшыра.

16. Муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органы әлеге Тәртипнең 15 пункты нигезендә тапшырыла торган хисапларның дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертларның максатчан файдаланылмавы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

17. Башка бюджетара трансфертлар бирелгән елдан соң килә торган елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар башка бюджетара трансфертлар бирелгән елдан соң килә торган елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә түләтелергә тиеш.

18. Әгәр башка бюджетара трансфертлар бирелгән елдан соң килә торган елның 1 гыйнвары хәленә карата муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган булса, башка бюджетара трансфертлар муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирелгән елдан соң килә торган елның 1 апреленә кадәр тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

19. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары әлеге Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

20. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланылмаган һәм (яки) муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан аны бирү шартлары бозылган, шул исәптән әлеге Тәртипнең 17 һәм 18 пунктлары нигезендә акча Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, аңа карата

Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

Башка бюджетара трансферлардан максатчан файдаланмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләтүгә китерә.

21. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---